ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

____20.04.2021__ М ө с л и м №____175_____

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районында авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү буенча комиссия төзү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районында авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү комиссиясен төзергә һәм 1 нче кушымта нигезендә раслaрга;
2. Авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү комиссиясе турында нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә расларга;
3. Авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү тәртибен 3 нче кушымта нигезендә расларга.
4. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни үсеш буенча урынбасары М.Р. Бәдретдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Р.Т. Демидов**

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның «___» _________
___ номерлы карарына
1 нче кушымта

Мөслим муниципаль районында авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Демидов Р.Т. | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, *комиссия рәисе;* |
| Бәдретдинова М.Р. | Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни үсеш буенча урынбасары, *комиссия рәисе урынбасары*; |
| Сәетгәрәева З.Ф. | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советының оештыру бүлеге баш белгече, *комиссия секретаре* (килешү буенча); |
| | *Комиссия әгъзалары:* |
| Әхмәтҗанов А.М. | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башлыгы урынбасары (килешү буенча); |
| Гарипов Р.Г. | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе (килешү буенча); |
| Бәдретдинов Н.А. | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башлыгы ярдәмчесе (килешү буенча); |
| Бубекова Н.А. | Мөслим муниципаль районының финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча); |
| Фролова Е.Е. | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы; |
| Хантимеров Р.Ф. | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше башлыгы; |
| Низамов И.Х. | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Ветераннар Советы рәисе (килешү буенча); |
| Солтанов Р.З. | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Иҗтимагый Советы вәкиле (килешү буенча); |
| Харисова Л.М. | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы вазыйфасын башкаручы; |
| Салихҗанов И.Ф. | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Мәдәният бүлеге» МКУ башлыгы; |

| | |
|---|---|
| Җаббаров И.Р. | Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы; |
| Фәтхуллина Г.Р. | Мөслим районындагы Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Якупов Д.Н. | «Мөслим үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы вазыйфаларын башкаручы, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча); |
| Шигапова Р.Ф. | ТР Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Мөслим муниципаль районындагы «Маяк» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләре халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт автоном учреждениесе директоры вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча). |

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның «___» _________
___ номерлы карарына
2 нче кушымта

**Авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга**
**бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү комиссиясе турында нигезләмә**

1. Бюджет чараларын бүлеп бирү турында карарлар кабул итү комиссиясе авыр тормыш хәлендә калган һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы территориясендә теркәлгән гражданнарның бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү турындагы гаризаларын карый һәм мондый ярдәм күрсәтү өчен нигезләр булу яисә булмау турында карарлар кабул итә.

2. Комиссия составы 17 әгъза санында Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

3. Комиссия утырышлары авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү тәртибенең 5.1 өлешендә каралган документлар тупланып кергән саен уздырыла.

4. Бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү һәм аның күләме турындагы карар, шулай ук бер тапкыр матди ярдәм күрсәтүдән баш тарту турындагы карар Комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән Комиссия тарафыннан гариза теркәлгән көннән алып 30 көннән дә артык булмаган вакытта кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Беркетмә Комиссия рәисе һәм секретаре тарафыннан имзалана.

5. Комиссия утырышы анда Комиссия составының яртысыннан күбрәге катнашса тулы хокуклы дип санала. Комиссия рәисе һәм секретаре тарафыннан имзаланган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Карар ачык тавыш бирү юлы белән күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта карар кабул ителмәгән дип санала.

6. Комиссия шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының Резерв фондында акча җитмәгән очракта, башка оешмаларга иганәчелек итү яки матди ярдәм күрсәтү турында үтенеч яза ала.

7. Комиссия эшчәнлеге белән идарә итүне Комиссия рәисе башкара, ә ул булмаганда – Комиссия рәисе урынбасары.

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының бер тапкыр матди ярдәм бүлеп бирү турында күрсәтмә проекты Комиссия тарафыннан бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү турында карар кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә Комиссия секретаре тарафыннан рәсмиләштерелә.

Мөрәҗәгать итүчегә Комиссия карар кабул итү турындагы хәбәрнамә Комиссия секретаре тарафыннан бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү турында карар кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә ясала һәм җибәрелә.

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның «___» _________
___ номерлы карарына
3 нче кушымта

**Авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Мөслим муниципаль районы башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 30 декабрендәге 659 номерлы карары нигезендә эшләнгән һәм авыр тормыш шартларында калган һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы территориясендә даими теркәлгән РФ гражданнарына бер тапкыр матди ярдәм күрсәтүнең хокукый, оештыру нигезләрен һәм механизмнарын билгели.

1.2. Авыр тормыш хәле дигәндә, гражданин үзе мөстәкыйль рәвештә хәл итә алмый торган шартлар аңлана: мөрәҗәгать итүченең яки аның якын туганының (хатыны, ата-анасы, баласы) авыр чире, янгын, су басу яки гражданинның мөлкәтенә зыян салган башка табигый бәла-казалар, аның тормыш эшчәнлеген объектив бозучы башка хәлләр. Әлеге шартлар Комиссия тарафыннан аерым карала.

## 2. Матди ярдәм күрсәтүнең финанс чыганагы

2.1. Авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм күрсәтүнең финанс чыганагы булып Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының чираттагы елга җирле бюджетта каралган резерв фонды акчалары, шулай ук иганәчеләр ярдәме белән табылган финанс чаралары тора.

## 3. Бер тапкыр матди ярдәм алу хокукына ия гражданнар категорияләре

3.1. Матди ярдәм күрсәтү хокукына, алар бәйле булмаган сәбәпләр аркасында бер кешегә уртача керем Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булаган гражданнарның түбәндәге категорияләре ия:

3.1.1. инвалид балалар;

3.1.2. Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары;

3.1.3. хәрби хәрәкәтләрдә катнашучы сугышчылар һәм аларның гаиләләре;

3.1.4. даими рәвештә чит кеше тәрбиясенә мохтаҗ ялгыз пенсионерлар һәм инвалидлар;

3.1.5. күпбалалы гаиләләр;

3.1.6. тәрбиясендә балигъ булмаган балалары булган тулы булмаган гаиләләр;

3.1.7 һәм 3.1.8 пунктларында күрсәтелгән гражданнар бер тапкыр матди

ярдәм алу өчен мөрәҗәгать иткән очракта, Татарстан Республикасында яшәү минимумы исәпкә алынмый:

3.1.7. янгыннан, су басудан яисә граждан мөлкәтенә зур зыян салган башка стихияле бәла-казадан зыян күргән затлар;

3.1.8. инвалидлык, авыр чир, ятимлек, күзәтүчесезлек белән бәйле рәвештә матди хәле авыр булган гражданнар һәм балигъ булмаган балалар.

## 4. Бер тапкыр матди ярдәм күләме

4.1. Бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм күрсәтү һәм аның күләме турында карар авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм күрсәтү Комиссиясе (алга таба - Комиссия) тарафыннан кабул ителә.

4.2. Бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм күләмен билгеләгәндә мөрәҗәгать итүченең матди-көнкүреш хәле, гаилә составы, бер кешегә уртача кереме, бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм күрсәтү турындагы гариза белән мөрәҗәгать итү өчен нигез булган сәбәпләр һәм шартлар исәпкә алына.

4.3. Бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм күләме, килеп туган хәлне объектив бәяләүдән һәм әлеге чыгымнарны каплау лимитларыннан чыгып билгеләнә.

4.4. Матди ярдәм күрсәтүдән баш тарткан очракта, комиссиянең дәлилләнгән карарлары мөрәҗәгать итүчегә Комиссия утырышыннан соң 10 көннән дә соңга калмыйча язма рәвештә җиткерелә.

## 5. Бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү тәртибе.

5.1. Авыр тормыш хәлендә калган гражданнар яки аларның законлы вәкилләре бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм күрсәтү мәсьәләсен хәл итү өчен, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетына килеп туган хәлне аңлатып, гариза белән мөрәҗәгать итәләр:

5.1.1. Мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы паспортының яисә башка документның һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлү күчермәсе;

5.1.2. гаилә составы турында белешмә;

5.1.3. матди ярдәм күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать иткәнчегә кадәр күп дигәндә бер ай алдан бирелгән 6 календарь ай эчендә гаилә әгъзаларының яки ялгыз яшәүче гражданның керемнәре турында документлар;

5.1.4. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан эшсезләр сыйфатында теркәү, эшсезлек буенча пособие алу һәм аның күләме турында документлар;

5.1.5. авыр тормыш хәлен раслаучы документлар, шул исәптән булачак акчалата чыгымнарны раслаучы документлар, яисә чыгымнар тотылган очракта-мөрәҗәгать итүче тарафыннан тотылган чыгымнарны раслаучы документлар;

5.1.6. гадәттән тыш хәл аркасында сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә зыян китерүне раслаучы белешмәләр (Мөслим муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлегеннән белешмә), ләкин гадәттән тыш хәл килеп чыккан көннән алты айдан да соңга калмыйча;

5.1.7. түләүле медицина ярдәме күрсәтү турында дәвалау учреждениеләре белән шартнамәнең күчермәсе;

5.1.8. билгеләнгән дәвалау кирәклеге турында белешмә;

5.1.9. инвалидлык турында белешмә;
5.1.10. тәрбиядә бала булу турында белешмә;
5.1.11. балигъ булмаган балаларның туу турында таныклыгы.

5.2. Мөрәҗәгать итүче тиешле вәкаләтле органнар тарафыннан төзелгән матди хәлне һәм көнкүреш шартларын тикшерү актын бирергә хокуклы.

5.3. Әлеге Тәртипнең 5.1 пунктында санап үтелгән документлар, билгеләнгән тәртиптә таныкланган күчермәләрдә дә, шулай ук төп нөсхәләрдә дә тапшырылырга мөмкин.

5.4. Гражданнан килгән гариза Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан карала һәм алга таба карау өчен авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү комиссиясе турындагы нигезләмә нигезендә Комиссиягә җибәрелә.

5.5. Бер тапкыр матди ярдәм алу хокукын раслаучы документлар бирелмәгән очракта, әлеге мөрәҗәгать каралмый.

5.6. Комиссиясе тарафыннан мөрәҗәгать итүченең тапшырылган белешмәләренең дөрес булмаган фактлары билгеләнгән очракта, мөрәжәгать итүче бер тапкыр матди ярдәм алу хокукыннан мәхрүм ителергә мөмкин.

5.7. Гадәттән тыш хәлләр аркасында документлар югалган очракта, мөрәжәгать итүчегә бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм түбәндәге очракта бирелергә мөмкин:

документларны һәм шәхесне таныклаучы документларны югалту мәсьәләсе белән мөрәҗәгать итү факты буенча җирле үзидарәнең тиешле органы белешмәләр.

5.8. Бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм бер календарь ел дәвамында бер тапкыр күрсәтелә.

5.9. Бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм күрсәтү һәм аның күләме турында карар, шулай ук бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм күрсәтүдән баш тарту турындагы карар Комиссия әгъзаларының гаризаны теркәгәннән һәм беркетмәне рәсмиләштергән көннән 30 көннән дә артык булмаган вакыт аралыгында күпчелек тавышы белән кабул ителә.

Беркетмә Комиссия рәисе һәм секретаре тарафыннан имзалана.

5.10. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү турында күрсәтмәсе Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү өчен нигез булып тора.

Мөрәҗәгать итүчегә Комиссия карары Комиссия секретаре тарафыннан бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү турында карар кабул итү турында хәбәрнамә юлламасы белән җиткерелә.

5.11.Бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм күрсәтү өчен акча Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты күрсәтмәсенә кул куелганнан соң 10 көн эчендә мөрәжәгать итүченең шәхси счетына максатчан билгеләнгән тиешле акчалата сумма күчерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

5.12. Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм суммасына салым салынырга тиеш түгел.